СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2021 с. Сарманово № 55

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 7 декабрендәге 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2001 елның 2 июлендәге 352-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2017 елның 7 декабрендәге 352 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар оешмалар, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенә еллык бухгалтерлык (финанс) хисабы, күрсәтелгән оешмалар һәм җәмгыятьләр «Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру (алга таба - бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсы) максатларында мондый хисаплылыкны тапшыру бурычыннан азат ителгән очракта, аның мәҗбүри